| СОВЕТ СТАРОМАТВЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ МАТВЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17.10.2022 ел** **№ 10**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге составына керүче Калморза торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 17.10.2022 елда узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Калморза торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, түбәндәгеләрдән тыш: *көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар,Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, аларның гаилә әгъзалары, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары* һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1. Калморза торак пунктында зират территориясен киртәләүне (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 113 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 79 кеше. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде 79 халык җыенында катнашучылар;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең Калморза торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

Сорау буенча карар кабул ителде: «2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Калморза торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме,түбәндәгеләрдән тыш:көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар,Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, аларның гаилә әгъзалары, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Калморза торак пунктында зират территориясен киртәләүне (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2. Иске Матвеевка авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен халыкка игълан итү http://menzelinsk.tatarstan.ruТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo tatarstan урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка житкерергә.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Д.Г.Шакиров
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Иске Матвеевка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Д.Г.Шакиров
(имза) (имзаны киңәйтү)